Раслыйм: Л.Н. Дәүләтбаева

МБУ «Арча ҮКС» директоры

# Лесхоз авыл китапханәсе каршында оешкан “Ак калфак” җирле татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы

Кереш:

“Ак калфак” оешмасы үсеп килүче буында милли үзаң формалаштыру; милли мәдәниятне һәм күпьеллык кыйммәтләрне торгызу, саклау һәм үстерү; туган телгә ихтирамны арттыру; милләтебезнең кием атрибутикаларын тегү–чигү һәм милли ризыклар әзерләү буенча мастер–класслар оештыру һ.б. шундый эшләр башкара.

Оешманың исеме: Ак калфак

Адресы: Татарстан җомһүрияте, Арча районa, Үрнәк бистәсе, Урман урамы, 45 йорт.

Оешкан елы: 2017 ел

Оештыручы: Шаймуллина Р.И. – китапханә мөдире

Клуб советы: Шаймуллина Р.И. – китапханә мөдире

Шавалиева Л.Р. – мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе

Валиуллина Г.Х. – лаеклы ялда

Оешманың эш урыны: китапханә

Катнашучылар: 40 яшьтән өлкәнрәкләр

Барлыгы оешмада: 7 әгъзә

Очрашу өч айга бер тапкыр.

Оешманың югары органы: җыелыш. Ул елга 2 тапкыр үткәрелә

**Хокук һәм йөкләмәләре.** Оешманың һәр члены үткәргән чараларга даими килергә һәм катнашырга үзенә йөкләнгән эшне күңел биреп башкарырга тиеш, һәр члены үзенең фикерен әйтергә һәм якларга, эшлекле тәкъдимнәр кертә ала.

**Лесхоз авыл китапханәсе каршында оешкан “Ак калфак” жирле татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасың нигезләмәсе**

## Максат:

Татар гаиләсен саклау, татар милләтен үстерү; гореф–гадәтләрне, телне саклап калу; икътисади һәм сәяси процессларда хатын-кызның ролен үстерү, балаларны милли мөхиттә тәрбияләү, сөйләм телләрен үстерү; балаларга әхлак тәрбиясе бирү; гаиләдә дәү әти-дәү әни һәм әти-әни тәрбиясе аша халкыбызның милли җәүһәрләрен киләчәк буынга тапшыру.

## Төп бурычлар:

-милли мәдәниятне һәм күпьеллык кыйммәтләрне торгызу, саклау һәм үстерү;

-туган телгә ихтирамны арттыру;

- татар хатынының гаиләдә, җәмгыятьтә тоткан ролен тасвирлау;

-үсеп килүче буыннарда игелек, әхлак, тирә-юньдәгеләргә ихтирамлы мөнәсәбәт, гаилә нигезләренә хөрмәт тәрбияләү;

-бүгенге җәмгыятьтә гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләрендә барган үзгәрешләрне күрсәтү һәм аларны бәяләү;

- аш-су, милли киемнәрнең сакланышы, әби-бабайлардан килгән гореф-гадәтләрне яшь буынга тапшыру, йолаларны саклау һәм бүгенге тормышка кайтаруны тасвирлаган матур үрнәкләр.